**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
14 февраля 2019 года

**Статья 1**

Внести в Бюджетный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II часть), № 10 (I часть), № 12 (IV часть); 2006, № 6 (I часть), № 12 (I часть); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III часть), № 10 (I часть); 2009, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 11 (I часть), № 11 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 7, № 10, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 12 (III часть); 2015, № 7 (I часть), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I) следующие изменения:

1) в статье $20^{1.3}$:

а) пункт 2 дополнить абзацем следующего содержания:

«Предоставление указанных субсидий местным бюджетам на софинансирование капитальных вложений в объекты капитального строительства и (или) приобретение объектов недвижимого имущества, которые не относятся (не могут быть отнесены) к муниципальной собственности, не допускается.»;

б) пункт 3 признать утратившим силу;

2) дополнить статьей $53^{5}$ следующего содержания:

«Статья $53^{5}$. **Перечень и оценка налоговых расходов Республики Татарстан**

1. Перечень налоговых расходов Республики Татарстан формируется в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан, в разрезе государственных программ и их структурных элементов, а также направлений деятельности, не относящихся к государственным программам.

2. Оценка налоговых расходов Республики Татарстан осуществляется ежегодно в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан с соблюдением общих требований, установленных Правительством Российской Федерации.

Результаты указанной оценки учитываются при формировании основных направлений бюджетной и налоговой политики Республики Татарстан, а также при проведении оценки эффективности реализации государственных программ Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Признать утратившим силу абзац седьмой пункта 4 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 10 мая 2014 года № 26-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 5).

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
01 марта 2019 года
№ 18-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $20^{1.3}$ статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирле бюджетларга күрсәтелгән субсидияләрне муниципаль милеккә карамаган (аңа кертелә алмаган) капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны финанслашу һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу өчен бирү рөхсәт ителми.»;

б) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $53^5$ статья өстәргә:

«$53^5$ статья. **Татарстан Республикасы салым чыгымнары исемлеге һәм аларны бәяләү**

1. Татарстан Республикасы салым чыгымнары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә дәүләт программалары

һәм аларның структур элементлары, шулай ук дәүләт программаларына карамый торган эшчәнлек юнәлешләре буенча төзелә.

2. Татарстан Республикасы салым чыгымнарын бәяләү, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Әлеге бәяләү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләгәндә, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 10 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 пунктының җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 5).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 18-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ